СОВЕТ ЦИПЬИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЧЕПЬЯ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«14» апрель 2025 ел № 152

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы турындагы Нигезләмәгә һәм гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Балтач районы прокуратурасының гражданнарның үзара салым турындагы Нигезләмәгә протест белдерүе, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге Уставы нигезендә Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге Советы карары белән расланган "Гражданнарның үзара салымы һәм гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибе турында Нигезләмә" гә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.2 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданнарның үзара салым акчалары дигәндә гражданнарның җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне хәл итү өчен башкарыла торган бер тапкыр түләүләре аңлашыла. Гражданнарның үзара салымы тәртибендә түләүләр күләме, гражданнарның саны җирлектә яшәүчеләрнең гомуми санының 30 процентыннан артмаска тиешле һәм түләүләр күләме киметелергә мөмкин булган аерым категорияләреннән тыш, җирлекнең барлык халкы өчен дә абсолют зурлыкта тигез итеп билгеләнә.».

1.2. Нигезләмәнең 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Әлеге Нигезләмәнең 1.2 пунктының 2 абзацында күрсәтелгән гражданнарның бер тапкыр түләүләрен кертү һәм куллану мәсьәләләре җирле референдумда, ә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясындагы 1 өлешенең 4, 4.1 һәм 4.3 пунктларында каралган очракларда гражданнар җыенында хәл ителә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (www.baltasi.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Чепья авыл
җирлеге башлыгы А.Г. Нотфуллин